Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең
Илтән-Бота авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

14 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 11 ноябрендә 17 сәгать 30 минутта, 2022 елның 11 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл җирлеге Илтән-Бота авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар, тыл хезмәтчәннәре һәм сугыш чоры балалары һәйкәле территориясен төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләүгә һәм җирлек милкенә рәсмиләштерүгә?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 232 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 118 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 118 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең Илтән-Бота авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл җирлеге Илтән-Бота авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар, тыл хезмәтчәннәре һәм сугыш чоры балалары һәйкәле территориясен төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү өчен түләүгә һәм җирлек милкенә рәсмиләштерүгә сез ризамы?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Илтән-Бота авылы, Совет урамы, 71 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Аппак авыл җирлеге башлыгы В.Н. Горбунова